**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
16.05.2019

**КАРАР**
№ 389

**Тәтеш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренә, Тәтеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларына хезмәт хакын түләү шартларын оештыру турында**

Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Тәтеш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренә, Тәтеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларына хезмәт хакын түләү шартларын оештыру турындагы нигезләмәне расларга.

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме саклангандa һәм алар тарафыннан шул ук квалификация үтәлгәндә, әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы күләме, аларга 2019 елның 31 мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Тәтеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карар нигезендә җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары исемнәре исемлеген төзүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында”

(PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 16 маендагы
389 номерлы карарына кушымта

**Тәтеш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренә, Тәтеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларына хезмәт хакын түләү турында нигезләмә**

1. Әлеге Тәтеш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренә, Тәтеш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларына хезмәт хакын түләү турында нигезләмә (алга таба - нигезләмә) “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУның бухгалтерия учеты һәм отчеты бүлеге, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Тәтеш үзәкләштерелгән клуб системасы” МБУның бухгалтерия учеты һәм отчеты бүлеге, “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” МКУның бухгалтерия учеты һәм отчеты бүлеге, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Үзәкләштерелгән бухгалтерия” МКУның эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хаклары күләмнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләрләрдән тора.

Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Муниципаль учреждениенең структур бүлекчәсе (бүлек) булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 23700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 21500 | |
| Муниципаль учреждениенең структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтеры) | | 21500 |
| Бүлек начальнигы | 17700 | 17700 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15300 | 15300 |
| Бухгалтер | 14400 | 14400 |

Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү өчен структурада һәрберсендә 5 кешедән дә ким булмаган кимендә 3 бүлекнең булуы шарт.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат санында кимендә 5 кеше булырга тиеш.

3. Җитәкчеләр һәм белгечләргә билгеләнә:

1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү:

| Эш стажы | Ай саен өстәмә түләү, процентта |
|---|---|
| 1 елдан алып 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан алып 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан алып 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан күбрәк | 15 |

2) вазыйфаи окладтан эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка 10 процент ай саен өстәмә түләү;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладтан 120 процент бер тапкыр түләнә торган түләү.

Әгәр хезмәткәргә ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча исәпләнә һәм декабрьдә түләнелә, эштән азат ителгән очракта, эштән азат ителгәннән соңгы көннән дә  соңга калмыйча.

Эшкә урнашканнан соң, беренче  ел  еллык түләүле отпуск биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә урнашкан көннән алып агымдагы елның 31 декабренә кадәр  исәпләнә.

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш нәтиҗәләре буенча премия бер ай һәм квартал өчен исәпләнергә мөмкин.

4. Җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\text{FOT} = \sum_{1}^{n} ((O_d\text{¿}+0,3*O_d)*k)\text{¿} * (1 + \text{t}) + \sum_{1}^{n} P*(1+t);$$

монда:

FOT - җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$- җитәкчегә һәм белгечкә хезмәт окладларын түләү өчен бер айлык акча суммасы;

0,3 * $O_d$ - тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;

P - җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык премиаль фонды *(әлеге нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә)*;

n - җитәкчеләр һәм белгечләрнең штат саны;

k -12 ай;

t - хезмәт өчен түләү буенча түләүләр исәпләү.